СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**17.12.2024**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 444**

Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2007 елның 2 мартындагы«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә , Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының 2023 елның 7 сентябрендәге 316 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 9.1 статья белән тулыландырырга:

« 9.1 статья. Анкета тапшыру, анкетадагы белешмәләрне үзгәртү турында хәбәр итү һәм мондый белешмәләрне тикшерү

1. Муниципаль хезмәткә кергәндә граждан анкета тапшыра.

2. Муниципаль хезмәткәр эшкә алучы вәкиленә (эш бирүчегә) анкетада булган белешмәләренең үзенә билгеле булган үзгәрешләре турында язма рәвештә хәбәр итә.

3. Анкетаның формасы, шул исәптән аңа кертелә торган белешмәләрнең исемлеге, аларны актуальләштерү тәртибе һәм сроклары Россия Федерациясе Президенты тарафыннан билгеләнә.

4. Анкетадагы белешмәләр эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең яисә ул вәкаләт биргән затның карары буенча тикшерелергә мөмкин. Анкетада булган белешмәләрне тикшерү, тиешле мәгълүматка ия булган гавами хакимият органнарына һәм оешмаларга язма рәвештә, шул исәптән дәүләт мәгълүмат системалары аша, рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү юлы белән Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының кадрлар хезмәте тарафыннан гамәлгә ашырыла. Тиешле мәгълүматка ия булган гавами хакимият органнары һәм оешмалар соратып алына торган мәгълүматны, әлеге рәсми мөрәҗәгать алынган көннән алып бер айдан да соңга калмыйча, бирергә тиеш.»;

1.2. 10 статьяның 3 пунктын түбәндәге эчтәлекле 13 пункт белән тулыландырырга:

«13. эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленә әлеге Нигезләмәнең 9.1 статьясында каралган анкетадагы белешмәләрнең үзенә мәгълүм булган үзгәрешләре турында язма рәвештә хәбәр итәргә, эшкә алучы (эш бирүче)

вәкиленең карары буенча үзгәргән белешмәләрдән тыш (алга таба - анкетадагы белешмәләр).»;

1.3. 11 статьяның 1 пунктындагы 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яисә) аны узган чорда муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәүне раслый торган ялган документлар һәм (яисә) белә торып ялган белешмәләр тапшыру,йә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү турында таныклыклый торган документлар һәм (яисә) белешмәләр тапшырылмау;»;

1.4. 11 статьяны түбәндәге эчтәлекле 10 - 22 пунктлар белән тулыландырырга:

«10. Муниципаль хезмәткәрнең коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт турында гаризасы (әлеге статьяда алга таба - гариза) «Муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы кодексы белән расланган рәвештә муниципаль хезмәткәрне эшкә алучы вәкиле исеменә язма рәвештә төзелә.

11. Гариза җирле үзидарә органының кадрлар хезмәтенә (кадрлар эшен гамәлгә ашыру өчен җаваплы вазыйфаи затка) (әлеге статьяда алга таба - кадрлар хезмәте) коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә планлаштырылган катнашу башланганчы тапшырыла.

12. Гаризаны теркәү «Муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы кодексы белән расланган форма буенча алып барыла торган гаризаларны теркәү журналына кергән көнне кадрлар хезмәте тарафыннан гамәлгә ашырыла. Гаризаларны теркәү журналының битләре номерланган, шнурланган һәм кадрлар хезмәте яки җирле үзидарә органы мөһере белән беркетелгән булырга тиеш.

13. Гаризаның теркәлү датасы, номеры, һәм әлеге гаризаны теркәгән кадрлар хезмәте затының вазыйфасы фамилиясе, инициаллары күрсәтелгән теркәлү турында тамгалы гариза күчермәсе муниципаль хезмәткәргә гаризаларны теркәү журналында имзасын куйдырып бирелә.

14. Кадрлар хезмәте гаризаны алдан карый һәм муниципаль хезмәткәрнең коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу мөмкин яисә мөмкин булмавы турында аңа дәлилләнгән бәяләмә әзерли (алга таба - дәлилләнгән бәяләмә). Кадрлар хезмәте дәлилләнгән бәяләмәне әзерләгәндә гариза биргән муниципаль хезмәткәрнең ризалыгы белән әңгәмәләр уздырырга һәм аннан язма аңлатмалар алырга мөмкин.

15. Дәлилле бәяләмәдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) коммерциячел булмаган оешмага карата кадрлар, оештыру-техник, финанс, матди-техник яки башка мәсьәләләр буенча , шул исәптән әлеге коммерциячел булмаган оешма тарафыннан билгеле бер эшчәнлек төрен һәм (яисә) аерым гамәлләрне башкаруга рөхсәт бирү белән бәйле карарлар кабул итү буенча муниципаль хезмәткәрнең вәкаләтләрен анализлау;

2) коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу очрагында муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү ихтималын анализлау.

16.Гариза һәм дәлилләнгән бәяләмә гариза теркәлгәннән соң җиде эш көне эчендә эш бирүче вәкиленә җибәрелә.

17. Гаризаны карау һәм мотивлаштырылган бәяләмә нәтиҗәләре буенча эш бирүче вәкиле түбәндәге карарларның берсен чыгара:

1) муниципаль хезмәткәргә коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуны рөхсәт итәргә;

1) муниципаль хезмәткәргә коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуны рөхсәт итмәскә;

3) гаризаны һәм дәлилле бәяләмәне җирле үзидарә органнары һәм муниципаль органының Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибен, муниципаль вазифалардагы затларның вазифа буенча үз-үзләрен тоту һәм мәнфәгатьләр каршылыкларын җайга салу таләпләрен үтәү комиссиясенә муниципаль хезмәткәрнең коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу очрагында аның мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү ихтималы булу яки булмауны карап тикшерүгә җибәрергә.

18. Әлеге статьяның 18 пунктының 2 пунктчасында каралган карарны кабул итү өчен муниципаль хезмәткәрнең коммерциячел булмаган оешма идарәсендә түләүсез нигездә катнашкан очракта мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү ихтималы булу нигез булып тора.

19. Әлеге статьяның 18 пунктындагы 3 пунктчасында каралган очракта, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтларын җайга салу комиссиясе гаризаны һәм дәлилләнгән бәяләмәне күрсәтелгән комиссиягә эш бирүче вәкиле җибәргән көннән алып җиде көн эчендә карый. Гаризаны карап чыгу һәм дәлилләнгән бәяләмә нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтларын җайга салу комиссиясе муниципаль хезмәткәрнең коммерциячел булмаган оешма идарәсендә түләүсез нигездә катнашкан очракта мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү ихтималы булу яки булмау турында карар кабул итә.

20. Әлеге статьяның 13 пунктында каралган карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә эшкә алучы вәкиле муниципаль хезмәткәргә коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт бирү яисә рөхсәт бирмәү турында карар кабул итә.

21. Кадрлар хезмәте әлеге статьяның 18 пунктының 1 һәм 2 пунктчаларында яисә 20 пунктында каралган карарларның берсен эш бирүче вәкиле кабул иткән көннән алып өч эш көне эчендә муниципаль хезмәткәргә гаризаларны теркәү журналында муниципаль хезмәткәрнең имзасын куйдырып, эш бирүче вәкиле кабул иткән карар турында язма рәвештә хәбәр итә йә муниципаль хезмәткәргә гаризаларны тапшыру турында хәбәрнамә белән һәм журналда бу хакта тамга куеп эш бирүченең кабул ителгән карары турында мәгълүматны почта элемтәсе аша җибәрә.

22. Гариза, дәлилләнгән бәяләмә һәм гаризаны карап тикшерүгә бәйле башка материаллар(алар булганда) муниципаль хезмәткәрнең шәхси эшнамәсенә теркәлә.»

1.5. 16 статьяның 4 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) әлеге Нигезләмәнең 9.1 статьясында каралган анкетаны;»;

1.6. 16 статьяның 4 пунктындагы 5 пунктчасында « һәм квалификация турында» сүзләрен өстәргә;

1.7. 16 статьяның 5 пунктында «белешмәләр» сүзләреннән соң «(анкетада булган белешмәләрдән тыш)» сүзләрен өстәргә;

1.8. 22 статьяның 5 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Нормалаштырылмаган эш көне өчен еллык өстәмә түләүле отпуск нормалаштырылмаган эш көне билгеләнгән җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләргә бирелә. Нормалаштырылмаган эш көне булган муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеге хезмәткәрләрнең вәкиллекле органы фикерен исәпкә алып кабул ителә торган җирле үзидарәнең тиешле органының күмәк шартнамәсе, килешүе яисә норматив акты белән билгеләнә.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат (http://pravo.tatarstan.ru)порталында

һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Советы рәисе** **М. П. Афанасьев**